КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 4 ноябрь г.Казань № 904

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 2 октябрь, 1209 нчы, 2024 ел, 15 июнь, 430 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 4 ноябрь, 904 нче карары редакциясендә)

# «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы

## «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммунал хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программысын гамәлгә ашыру өлкәсендә стратегик өстенлекләр

### I. Торак һәм торак-коммуналь өлкәнең агымдагы хәлен бәяләү

2011 елдан 2024 елга кадәр Татарстан Республикасы территориясендә торак тапшыруның гомуми күләме 37 580,7 мең кв.метр тәшкил итте, максималь күләм 2024 елда теркәлде.

2024 ел нәтиҗәләре буенча торак тапшыру күләме 3 452,7 мең кв.метр тәшкил итте, шуларның инвестицион күпфатирлы йортлар – 940,9 мең кв.метр, социаль ипотека программасы буенча – 161,8 мең кв.метр, шәхси торак төзелеше – 2 350,0 мең кв.метр.

Халыкның торак мәйданы белән уртача тәэмин ителеше бер кешегә 30,3 кв.метр тәшкил итә.

Торак төзелешен үстерүгә уңай йогынты ясаучы законнар һәм оештыру чаралары торак төзелеше өлкәсендә конкуренцияне үстерү һәм административ процедураларны киметү булды. Территорияләрне планлаштыру проектларын әзерләү, проект документациясен эшләү, инженер эзләнүләре һәм проект документациясе нәтиҗәләренең дәүләт экспертизасы, төзелешкә рөхсәт бирү, дәүләт төзелеш күзәтчелеге процедуралары гадиләштерелде.

Торакка ихтыяҗны стимуллаштыру ипотека торак кредитлау базарын үстерү белән тәэмин ителде. Ипотека торак кредитлауның тиз үсеше өчен законнар һәм икътисадый шартлар тәэмин ителде.

2020 елда пандемия аркасында макроикътисадый хәлнең начарлануы шартларында торак төзелешен һәм ипотека торак кредитларын хуплау максатында гражданнарга яңа төзелешләрдә торак сатып алу өчен ташламалы ставкалар буенча ипотека торак кредитлары (заемнар) бирү программасы эшләтеп җибәрелде.

Дәүләт торак сәясәтен гамәлгә ашыру максатында, гражданнарның, шул исәптән өлешле төзелештә катнашучыларның да, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау гарантияләрен арттыруга юнәлдерелгән 2017 елда «Өлешле

төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» җәмәгать-хокукый компаниясе төзелде.

Яңа алданган гражданнар  – өлешле төзелештә катнашучыларның барлыкка килү мөмкинлеген тулысынча бетерү максатында, 2020 елда өлешле төзелешнең киңкүләмле реформасы үткәрелде һәм, эскроу счетларын кулланып, торак төзелешен финанслау өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә күчү башкарылды.

Массакүләм торак төзелеше чорында йорт салучыларның күпфатирлы йортларны төзү һәм аларда өлешле төзелеш объектларын аларның акчалары күрсәтелгән күпфатирлы йортларны төзү өчен төзүчеләр тарафыннан җәлеп ителгән өлешле төзелештә катнашучы гражданнарга өлешле төзелеш объектларын тапшыру буенча  үз йөкләмәләрен намуссыз башкару фактлары билгеләнде (ачыкланды).

Иң кискен социаль проблемаларның берсе булып  Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләтнең торак белән тәэмин итү бурычлары булган гражданнар категорияләрен торак белән тәэмин итү проблемасы кала бирә.

Татарстан Республикасында 2020 – 2024 еллар дәвамында 55 гаиләнең федераль бюджет хисабына 155,2 млн. сум күләмендә торак мәсьәләсе хәл ителде(радиация аварияләре һәм катастрофалары нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнар һәм аларга тиңләштерелгән затлар; билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри күченүчеләр дип танылган гражданнар; Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән урыннардан күчеп киткән гражданнар).

Татарстанда ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак белән тәэмин итү механизмы эшләнде, бу дәүләтнең әлеге категория гражданнарны торак белән тәэмин итү бурычларын нәтиҗәле үтәргә мөмкинлек бирә.

2007 елдан 2012 елга кадәр ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга 733 торак сертификаты бирелде. 2013 елдан 2024 елга кадәр махсуслаштырылган торак фондының торак биналары белән 5 349 кеше тәэмин ителде.

Гражданнарның торак шартларын яхшырту юнәлешләренең берсе булып авария хәлендәге торак фондын бетерү тора. Әлеге юнәлеш гражданнарны авария хәлендәге торaклардан күчерү чаралары кысаларында, «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе катнашында башкарыла.

2019 – 2024 елларда 21,15 мең кв.метр авария хәлендәге торак күчерелгән, шундый торакта яшәүче 1,844 мең кеше күчерелгән. 2025 ел этабы буенча (2025 – 2026 елларда гамәлгә ашырыла) 1,78 мең кв.метр авария хәлендәге торакны күчерү планлаштырылган.

Яшәү өчен яраксыз торак фондын тотрыклы киметүгә комачаулый торган төп фактор булып торак фондын тикшерү нәтиҗәләре буенча авария хәлендә дип танылган торак фондының  ел саен арту һәм, шуңа күрә,  туплануы тора.

Авария хәлендәге торак фондыннан күчерү вакытында торак бүлмәләр хуҗаларының хокукларын гамәлгә ашыру максатында, 2017 елның 1 гыйнварыннан соң шундый дип танылган авария хәлендәге торакны күчерүнең яңа программасын булдыру юлы белән торак фондын яңартуның даими эшли торган системасын булдыру кирәк.

## II. Татарстан Республикасының торак һәм торак-коммуналь өлкәдә дәүләт сәясәтенең өстенлекләре һәм максатлары тасвирламасы

Дәүләт сәясәтенең шәһәр мохитен төзекләндерү мәсьәләләрендәге өстенлекләре Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорда һәм 2036 елга кадәр перспективада Россия Федерациясе үсешнең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы, Россия Федерациясе Президентының күрсәтмәсе нигезендә формалаштырылган Россия Федерациясенең 2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр план чорына үсешнең илкүләм максатларына ирешү буенча бердәм план, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 31 октябрендәге 3268-р номерлы боерыгы белән расланган 2035 елга кадәр фаразлар белән 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең төзелеш тармагын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү стратегиясе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 28 декабрендәге 4146-р номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең пространстволы үсеш стратегиясе, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Стратегия-2030) белән билгеләнде.

Татарстан Республикасының торак һәм торак-коммуналь өлкәдә дәүләт сәясәтенең төп өстенлекләре булып гражданнарның барлык категорияләре өчен торакның мөмкинлеген һәм уңайлы торак фондының күләме халык ихтыяҗларына туры килүен тәэмин итү тора.

Торак өлкәсендә өстенлек – халыкның төрле төркемнәренең ихтыяҗларына туры килгән торак базарында тәкъдимнәр үсешенә шартлар тудыру, шулай ук Россия Федерациясенең барлык гражданнары өчен торакның мөмкинлеген арттыру, шул исәптән:

шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин ителгән җир кишәрлекләренең нәтиҗәле базарларын формалаштыру;

массакүләм торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрен социаль, инженерлык, коммуналь һәм транспорт инфраструктурасы белән тәэмин итү;

инновацион, шул исәптән энергия саклаучы, технологияләр кулланып төзелеш комплексы һәм төзелеш материаллары, әйберләр һәм конструкцияләр җитештерүне үстерү;

торак төзелеше өлкәсендә инновацион технологияләр кертүгә ярдәм итү, төзелеш материаллары, әйберләр һәм конструкцияләрнең эчке җитештерүен үстерү;

территорияләрнең комплекслы үсешенә ярдәм итү;

аз катлы төзелешне стимуллаштыру;

торак өлкәсендә торакның мөмкинлеген арттыруны тәэмин итү өлешендә үсешнең бердәм институты эшчәнлеген камилләштерү;

арендалы торак базарын үстерү.

Торак-коммуналь өлкәдә өстенлек – халык ихтыяҗларына туры килгән уңайлы торак фонды күләмен тәэмин итү, шул исәптән:

торак фондының тузуын киметүне тәэмин итүче шартлар тудыру, шул исәптән уртача вакытлы перспективада аварияле торакның җыелган күләмен киметү;

күпфатирлы йортлар белән идарә итүнең норматив хокукый һәм методологик нигезен камилләштерү юлы белән күпфатирлы йортлар белән нәтиҗәле идарә итү өчен торак милекчеләрен оештыруга ярдәм итү;

торак-коммуналь өлкәдә модернизация.

Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең стратегик максатларына һәм бурычларына ирешү максатларында «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының максатлары, структурасы һәм күрсәткечләр системасы эшләнде (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт программасы).

1 нче максат: гражданнарны торак белән тәэмин итү.

2 нче максат: торак фондын яңарту.

3 нче максат: яшәү өчен яраксыз торак фондын тотрыклы киметү.

4 нче максат: беренчел базарда торактан һәркем файдалана алырлык булуны арттыру.

5 нче максат: коммуналь инфраструктураны модернизацияләү программасын гамәлгә ашыру һәм күрсәтелә торган коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту.

6 нчы максат: эчәргә яраклы су белән тәэмин итү һәм су әзерләү объектларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү).

## III. Стратегик өстенлекләр, илкүләм максатлар һәм Стратегия-2030 максатлары, Россия Федерациясе дәүләт программалары күрсәткечләре белән үзара бәйләнеш турында белешмәләр

Татарстан Республикасы дәүләт программасының максатлар системасы һәм бурычлары Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәр перспективада Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы белән билгеләнгән 2030 елга кадәрге чорга илкүләм үсеш максатларын, Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе нигезендә 2030 елга кадәр һәм 2036 елга кадәр план чорына Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча бердәм планны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 31 октябрендәге 3268-б номерлы боерыгы белән расланган 2035 елга кадәр фаразлар белән 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең төзелеш тармагын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү стратегиясен, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 28 декабрендәге 4146-б номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең пространстволы үсеш стратегиясен, Стратегия-2030 исәпкә алып формалаша.

Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру турыдан-туры түбәндәгеләргә юнәлдереләчәк:

«Тормыш өчен уңайлы һәм имин мохит» Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатына ирешүгә:

күбрәк гражданнарның торак шартларын яхшырту өчен шартлар тудыру максатында торак төзелеше күләмен арттыру;

яшәү өчен яраклы булмаган торак фондын тотрыклы кыскарту;

комплексly модернизация планнары белән каралган коммуналь инфраструктура объектларын төзү, реконструкцияләү (модернизацияләү), капиталь ремонтлау чараларын гамәлгә ашыру;

2019 елдан башлап эчәргә яраклы су белән тәэмин итү һәм су әзерләү объектларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) саны;

«Татарстан-2030 – глобаль конкурентлыкка сәләтле тотрыклы төбәк, «Идел-Кама» үсеш полюсы драйверы төп стратегик максатны гамәлгә ашыруга. Татарстан – кеше капиталының, институтларның, инфраструктураның, икътисадның, тышкы интеграциянең (Россиянең үзәк Евразия регионы) һәм эчке пространствоның үзара бәйләнгән үсеше сыйфаты буенча лидер; үсеш темплары алдан бара торган, хезмәтнең халыкара бүленешенә керү дәрәҗәсе югары булган төбәк», шулай ук Татарстан Республикасының төп стратегик максатына ирешүгә:

«Кеше капиталы: тупланган кеше капиталы Татарстан Республикасының көндәшлеккә сәләтлелеген тәэмин итә. Татарстан Республикасы югары яшәү сыйфатына ирешү шартларын тудыру аша төп актив буларак кеше капиталын туплауда лидерлык итә»;

«Пространство, реаль капитал: балансланган территориаль-пространство үсеше мохитнең конкурентлык сәләте югары дәрәҗәдә булуын тәэмин итә; инфраструктура глобаль рәвештә конкурентлыкка сәләтле. Җитештерү фондлары нәтиҗәле файдаланыла».

## IV. Торак һәм торак-коммуналь өлкәләрдә дәүләт идарәсе бурычлары, аларны нәтиҗәле хәл итү ысуллары

Татарстан Республикасы дәүләт программасы күрсәткечләренә ирешү максатларында түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. торак төзелеше күләмен арттыру.

2. Төзелеш тармагын модернизацияләү, стандарт торак төзелешенә дәүләт ярдәме механизмнарын камилләштерү.

3. Торак сатып алганда һәм гражданнарның торак шартларын яхшыртканда дәүләт ярдәменең өстәмә чараларын күрсәтү, дәүләт йөкләмәләрен һәм социаль гарантияләрне үтәү.

4. Гражданнарны, аларның торак хокукларын үтәүне тәэмин итә торган яшәү өчен яраксыз торак фондыннан күчерү механизмнарын булдыру.

5. Торак фондының сыйфатын яхшырту.

6. Яшәү шартларының уңайлылыгын арттыру, коммуналь инфраструктураның алга таба үсеше һәм ышанычлылыгын арттыру.

7. Су әзерләүнең перспектив технологияләрен (оборона-сәнәгать комплексы оешмалары тарафыннан эшләнгән технологияләрне кертеп) файдаланып, су белән тәэмин итү системасын модернизацияләү юлы белән эчәргә яраклы суның сыйфатын яхшырту.

8. Архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалыкта дәүләт сәясәтенең нәтиҗәлелеген арттыру өчен шартлар тудыру.

Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатларына һәм бурычларына ирешү түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру аша башкарыла:

«Яшәү өчен инфраструктура» илкүләм проекты составына керә торган «Торак», «Коммуналь инфраструктураны модернизацияләү» федераль проектлары;

«Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү», «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак урыннар белән тәэмин итү», «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларның техник торышын яхшырту», «Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» төбәк проектлары;

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы эшчәнлеген тәэмин итү һәм архитектура, шәһәр төзелеше, граждан һәм сәнәгать, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру», «Татарстан Республикасы дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе эшчәнлеген тәэмин итү» һәм «Төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру» процессллы чаралар комплекслары.

Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен, Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү һәм бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләрен, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында капитал салуларны гамәлгә ашыру турында карарларны раслый торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары исемлеге

| Т/с | Документ тибы | Документ төре | Документ исеме | Реквизитлары | Эшләүче | Документ текстына гиперссылка |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. «Яшәү өчен яраксыз булган торак фондын тотрыклы киметүне тәэмин итү» төбәк проекты | | | | | | |
| 1.1. | Субсидияләрне формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләре | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары | Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында | 20.09.2019 № 851 | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | https://pravo.tatarstan.ru/npa_kabmin/post/?npa_id=425648 |
| 1.2. | Субсидияләр бирү тәртибе | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары | Җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында | 31.05.2021 № 425 | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | https://pravo.tatarstan.ru/npa_kabmin/post/?npa_id=783328 |
| 2. «Күпфатирлы йортларның техник торышын яхшырту» төбәк проекты | | | | | | |
| 2.1. | Субсидияләр бирү тәртибе | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларга ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешма- | 20.06.2022 № 589 | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь | https://pravo.tatarstan.ru/npa_kabmin/post/?npa_id=1002451 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында | | хуҗалык министрлыгы | |
| 3. «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» | | | | | | |
| 3.1. | Субсидияләр бирү тәртибе | | Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең яшь гаиләләргә торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләүләр бирү вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү һәм бүлү тәртибен раслау турында | 14.11.2024 № 1000 | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | https://pravo.tatarstan.ru/npa_kabmin/post/?npa_id=1506896 |
| 3.2. | Субсидияләр бирү тәртибе | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары | Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру турында | 11.10.2024 № 877 | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | https://pravo.tatarstan.ru/npa_kabmin/post/?npa_id=1478041 |